Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

# КАРАРЫ

**№ 133** **26 апрель 2019 ел**

**«2018 елда Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында»**

Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2018 ел өчен Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны, керемнәрне чыгымнардан 7887,5 мең сумга арттырып, керемнәр буенча 7911,5 мең сум, чыгымнар буенча 24,0 мең сум һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1.1. 2018 ел өчен бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә;

1.2. 2018 ел өчен бюджет керемнәрен әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә;

1.3. 2018 елда тармак структурасы буенча бюджет чыгымнарын 4нче кушымта нигезендә һәм чыгымнарның функциональ структурасы бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре буенча бюджет чыгымнарын бүлүне әлеге карарга 3нче кушымта нигезендә расларга.

2. Югары Шепкә авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Югары Шепкә авыл җирлеге башкарма комитетының Резерв фонды хисабына файдалану турында хисапны әлеге карарга 5 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

3.Әлеге карарны авыл җирлеге стендларына элү юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Югары Шепкә авыл җирлеге**
**Советы башлыгы** **А.Х.Ишматов**